# КАРАР

2020 елның 13 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 11.11.2020, 12.11.2020 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены протоколы төзелде.:

"2021 елда, 400 сум узара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Лубян авыл җирлегендә Лубян авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, балачактан Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлардан тыш) алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне:

- Лубян авылында юлларны карап тору;
- Лубян авылында урамнарына яктырткычлар кую, энергияне саклый торан лампалар сатып алу, урнаштыру һәм ремонт;
- Лубян авылын төзекләндерү;
- Лубян авылында комплектлаштыручы фитинглар белән тирән басымлы насослар һәм түбән басымлы полиэтилен торбалар сатып алу;
- Лубян авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру:
- Лубян авлында халык дружиналары эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудыру, җәмәгать тәртибен саклауда катнашкан гражданнарга һәм аларның оешмаларына ярдәм күрсәтүне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме ?»

« ӨЧЕН» « КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 939 кеше, җыенда катнашучылар саны 474 кеше теркәлгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 470 кеше тавыш бирде;
«юк» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 4 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2 "2021 елда, 400 сум узара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Лубян авыл җирлегендә Лубян авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 Төркем инвалидларыннан, 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр һәм ялгыз аналар, балачактан Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлардан тыш) алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне: - Лубян авылы юлларын карау;
- Лубян авылы урамнарына яктырткычлар кую, һәм энергияне саклый торан лампалар сатып алу, урнаштыру, ремонт эшләре;
- Лубян авылын төзекләндерү;
- Лубян авылында комплектлаштыручы фитинглар белән тирән басымлы насослар һәм түбән басымлы полиэтилен торбалар сатып алу;
- Лубян авылында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру:
- Лубян авлында халык дружиналары эшчәнлеге өчен уңайлы шартлар тудыру, җәмәгать тәртибен саклауда катнашкан гражданнарга һәм аларның оешмаларына ярдәм күрсәтүне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме ?»

« ӨЧЕН» « КАРШЫ»

- кабул ителгән дип таныргa.

3. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылып , гражданнар Җыенының нәтиҗәсен игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: www.pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Лубян авыл
җирлеге Башлыгы Г.Ф.Тежикова